


## ГОМЕР

*Төгәллисе бик күп эшләрем бар,*
*Ләкин гомер шактый кыскарды;*
*Һаман әле саклыйм хәтеремдә*
*Кырда ятып калган дусларны.*

*Алар белән кичтек ут-давылны,*
*Сынык-сыныкларны бүлештек,*
*Кайгы төшсә, бергә уртаклаштык,*
*Шатлык килсә, бергә бүлештек.*

*Авыр сугыш билән киң кырларны,*
*Каннар белән җирне сугарды,*
*Үзәгемне өзеп ярам сызлый,*
*Хәтерлим дә менә шуларны.*

*Төш аралаш яшен яшьнәсә дә,*
*Мин фронтта кебек хис итәм,*
*Әйтерсең, лә туп һәм бомбаларның*
*Шартлау тавышларын ишетәм.*

1961

**Адрес:**
Чакмагыш авылы,
Кооператив ур., 44 А

**Тел.:** 3—13—46

**БУКЛЕТ**

Т¯зїчесе: Сафиуллина Ф.Г.

Чакмагыш
л¢м¢ - ара ïз¢кл¢штерелг¢н китапхан¢л ¢р системасы



ЧАКМАГЫШ—2009

# Нурулла Әхьяр улы Гайсин

1914 елның 2 ноябрендә Уфа губернасының Әхмәт авылында туа.

Җиде яшендә тулы ятим калган малай туганнары тәрбиясендә үсә. 1930 елда ул авыл мәктәбен тәмамлап, Уфага телеграфистлар курсына укырга керә. Аны тәмамлагач, Баймак районында телеграфист һәм Зилаир орлыкчылык совхозында элемтә бүлеге мөдире булып эшли.

1933 елда Зоя (Свияжск) шәһәрендә төзелеш институты рабфагында укый. Шунда укыганда Н. Гайсин иҗат эше белән шөгыльләнә башлый.

Әдәбият дөньясына якынрак булу өчен, 1934 елда ул Казанга килә. Башта су юлы инженерлары әзерли торган институт рабфагында, аннары Казан дәүләт педагогия институтының әзерлек курсларында укый. Педагогия институтында укыган елларында яшь шагыйрьнең "Ватаным өчен", "Яшьлек таңы" исемле беренче шигырь җыентыклары басылып чыга. Институтны тәмамлагач, ул Ютазы районы Кәрәкәшле урта мәктәбендә укытучы булып эшли.

Бөек Ватан сугышы елларында һава оборонасы гаскәрләрендә взвод һәм батарея командиры булып хезмәт итә.

Сугыштан соң Уфада чыга торган "Кызыл тан" газетасында әдәби хезмәткәр, соңрак Казан татар театр училищесында уку-укыту бүлеге мөдире һәм укытучы булып эшли.

1952—53 елларда ул яңадан Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1955 елдан язучылык эше белән генә шөгыльләнә

Шагыйрь Нур Гайсин әдәбият сөючеләргә барлыгы ике дистәдән артык китабын бүләк итте. Алар: "Айлы кичтә", "Тайгада очрашу", '"Җир чәчәктә", "Өмет тулы хыялым", "Минем туганнарым", "Таныш моң" һ. б. китаплар. Нигездә ул балалар өчен язды: шигырьләр, пьесалар, хикәяләр, әкиятләр, мәсәлләр... Алар арасында "Таза Мортаза" поэмасы, тәрҗемәи хәленә нигезләп язылган "Кызыл ыштанлы малай" исемле повесте бар... Аның шигырьләре мәктәп дәреслекләренә кереп, ничә буын укучылар күңелендә калды.

Н. Гайсин драма әсәрләр авторы буларак та билгеле. Әлмәт колхоз-совхоз театры сәхнәсендә аның 1947 елда „Давыллар эчендә" драмасы, 1948 елда „Айсылуның мәхәббәте" комедиясе, 1950 елда „Юл ачык" исемле пьесалары куелды. 1958 елда Н. Гайсинның „Айлы кичтә" дигән шигырьләр җыентыгы басылып чыкты.

1953 елда Нур Гайсинны‹ „Безнең мәктәп" исемле шигырьләр җыентыгы рус теленә дә тәрҗемә ителеп басылды.

Н. Гайсин А. Бартоның „Заставада", „Елак кыз" әсәрләрен, Мөхтәревнның „Галләм семьясы", Бараташвилиның „Чикерткә" комедияләрен һәм башка язучыларның әсәрләрен тәрҗемә итте.

Нур Гайсин 1995 елның 1 декабрендә вафат булды.



## Китаплары:

- Ватаным өчен: Шигырьләр.— Казан: Татгосиздат, 1937.
- Зәңгәр күктә: [Шигырь].—Казан: Татгосиздат, 1938. — 8 б.
- Яшьлек таңы: [Шигырьләр].—Казан: Татгосиздат, 1938.
- Түтәлләр: [Шигырьләр].—Казан: Татгосиздат, 1948. — 19 б.
- Безнең мәктәп: (Шигырьләр).—Казан: Татгосиздат, 1950.
- Минем әнием: (Шигырьләр).— Казан: Татгосиздат, 1951.
- Безнең дуслар: Шигырьләр.— Казан: Татгосиздат, 1952.
- Тайгада очрашу: Ерак Көнчыгыш турында шигырьләр.— Казан: Таткнигоиздат, 1956.
- Таза Мортаза. [Шигырьләр].—Казан: Таткитнәшр., 1958.
- Айлы кичтә: Шигырьләр.— Казан: Таткитнәшр., 1958.— 116 б. портр.
- Хәерле иртә: (Шигырьләр).—Казан: Таткитнәшр., 1962.— 24 б. ил.
- Шигырьләр. Поэмалар,—Казан: Таткитнәшр., 1964.—95 б.
- Җир чәчәктә: Шигырьләр, мәсәлләр.—Казан: Таткитнәшр., 1966.
- Дуслык бакчасы: Шигырьләр, мәсәлләр һәм әкиятләр.— Казан: Таткитнәшр., 1967.—52 б., ил.
- Яна өйгә күчкәч: Сайл. шигырьләр, әкиятләр һәм поэмалар.— Казан: Таткитнәшр., 1969.
- Мәктәптә яз: [Саил. әсәрләр]. Җ. Тәрҗеманов кереш сүзе.— Казан: Таткитнәшр., 1974.
- Җирдәге кояш: Шигырьләр.—Казан: Таткитнәшр., 1979.— 48 б., ил.
- Кызыл штанлы малай. (Мин ничек дүрт үлемнән исән калдым): Повесть.— Казан: Таткитнәшр., 1981.
- Өмет тулы хыялым: Шигырьләр.— Казан:, Таткитнәшр., 1983.
- Наша школа: Стихи/Пер. с татар. А. Мелуеникова.— Казань: Татгосиздат, 1953.